РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БУГУЛЬМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.05.2019 ел №22

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2019 елның 9 гыйнварында чыгарган «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 8нче карарына үзгәрешләр кертү турында**

Законга туры китерү максатында

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2019 елның 9 гыйнварында чыгарган «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 8нче карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 бүлекнең 1.5 пунктының 10 абзацын яңа басмада бәян итәргә:

"планлаштыру структурасы элементы" - зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек эшчәнлеге алып бару территориясе».

1.2. 5 бүлектәге 5.8 пункны яңа басмада бәян итәргә:

«5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип табылганда, мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында, башкарма комитет, күпфункцияле үзәк, оешма яки 210нчы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1нче өлешендә каралган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында, алга таба башкарылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

2. Карар текстының калган өлешен үзгәрешсез калдырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**Р.Т. ХУҖИЕВ.**